МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

23.11.2021 г.Казань № 862

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2021 елның 14 декабрендә 8401 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Өч яшьтән алып җиде яшькә кадәрге балага айлык акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2020 елның 25 апрелендәге 263 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Өч яшьтән алып җиде яшькә кадәрге балага айлык акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2020 елның 25 апрелендәге 263 номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 13.07.2020 №503, 02.10.2020 №692, 09.06.2021 №410, 06.08.2021 №567 реквизитлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне кертергә.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 23.11.2021 №862 боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Өч яшьтән алып җиде яшькә кадәрге балага айлык акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2020 елның 25 апрелендәге 263 номерлы боерыгына кертелә торган үзгәрешләр

Исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Өч яшьтән җиде яшькә кадәрге балага айлык акчалата түләү билгеләү һәм аны түләп бару буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Өч яшьтән җиде яшькә кадәрге балага айлык акчалата түләү билгеләү һәм аны түләп бару буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең кушымтада бирелә торган административ регламентын (алга таба – Регламент) расларга.»;

Өч яшьтән җиде яшькә кадәрге балага айлык акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (алга таба – Регламент):

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Өч яшьтән җиде яшькә кадәрге балага айлык акчалата түләү билгеләү һәм аны түләп бару буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты»;

1 бүлектә:

1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Өч яшьтән җиде яшькә кадәрге балага айлык акчалата түләү билгеләү һәм аны түләп бару буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба – Регламент) өч яшьтән җиде яшькә кадәрге балага айлык акчалата түләү билгеләү һәм аны түләп бару буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (алга таба – дәүләт хезмәте) стандартын һәм тәртибен билгели.»;

1.3.1 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«1.3.1. Идарә (бүлек) урнашкан урын, аның эш графигы, белешмә телефоннары, электрон почта адресы турында мәгълүмат Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – Министрлык) рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү реестры» дәүләт мәгълүмат системасында һәм «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба – Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы) урнаштырылган.»;

1.3.2 пунктның 2 пунктчасындагы дүртенче абзацында «(алга таба – Бердәм портал)» сүзләрен төшерергә;

2 бүлектә:

2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Күрсәтелә торган дәүләт хезмәте атамасы

Өч яшьтән алып җиде яшькә кадәрге балага айлык акчалата түләү (алга таба – айлык акчалата түләү) билгеләү һәм аны түләп бару.»;

2.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Башкарма хакимият органы (учреждение) атамасы

«Татарстан Республикасы муниципаль районында яисә шәһәр округында Үзәк бүлекчәсе йөзендә «Республикасы матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе.»;

2.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау

Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып айлык акчалата түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар тора.»;

2.4 пунктта:

2.4.2 пунктының икенче абзацында «дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы» сүзләрен «Бердәм портал» сүзләренә алмаштырырга;

2.4.5 пунктчасын түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

«2.4.5. Мөрәҗәгать итүчегә айлык акчалата түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар турында хәбәр итү айлык акчалата түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул ителгән көнне гамәлгә ашырыла.

Айлык акчалата түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул итү турында хәбәр юлланган мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу өчен шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта, айлык акчалата түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту турында) карар күчермәсен бирү мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.»;

2.5 пунктның 2.5.1 пунктчасында:

1 пунктчаның өченче абзацында «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрләрнең) бердәм порталы» сүзләрен «Бердәм портал» сүзләренә алмаштырырга;

13 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13) һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларында укучыларга, фән-педагогика кадрларын әзерләү программалары буенча көндезге рәвештә белем алучы аспирантларга һәм дини белем бирү оешмаларында укучы фән-педагогика кадрларына түләнә торган стипендияләр, шулай ук медицина күрсәткечләре буенча аларның академия отспускысында булуы чорына гражданнарның күрсәтелгән категорияләренә компенсация түләүләре күләме хакында документ күчермәсе;»;

17 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өч яшьтән җиде яшенә кадәр (тулганчы) балага айлык акчалата түләү турында» 2021 елның 22 октябрендәге 995 номерлы карары белән расланган Өч яшьтән җиде яшенә кадәр (тулганчы) балага айлык акчалата түләү тәртибе һәм шартларының (алга таба – Тәртип һәм шартлар) 30 пунктының «а» пунктчасында һәм (мөрәҗәгать итүче яисә аның гаилә әгъзалары Россия Федерациясе җинаять үтәтү системасына караган оешмаларның һәм органнарның, федераль иминлек хезмәте органнарының, Россия Федерациясе дәүләт сагы органнарының, эчке эшләр органнарының хезмәткәрләре булып торган булсалар) һәм «е» пунктчасында каралган керемнәр күләме турындагы документ күчермәсе;»

2.8 пунктта:

2.8.1 пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гаризаны Бердәм портал яисә Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша яисә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә документларның тулы комплекты белән тапшырылмавы»;

2.8.2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.8.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре:

а) үзенә карата гариза тапшырыла торган баланың вафат булуын дәүләт теркәвенә алу;

б) гаиләнең җан башына уртача кереме күләменең айлык түләү билгеләү өчен мөрәҗәгать итү датасына Татарстан Республикасында билгеләнгән халыкның җан башына яшәү минимумы күләменнән артык булуы;

в) гаризада дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүматлар булуы;

г) мөрәҗәгать итүченең һәм аның гаилә әгъзаларының милегендә түбәндәгеләрнең булуы:

«торак» һәм «торак корылма» билгеләнеше белән ике һәм аннан күбрәк бина, суммар мәйданы гаилә әгъзасы саннарына 24 кв.метрдан тапкырлап исәпләгәндә зуррак булган «торак» һәм «торак урын» билгеләнеше белән бүлмәләр (Россия Федерациясе субъектының вәкаләтле органы яки муниципаль берәмлек тарафыннан күпбалалы гаиләгә социаль ярдәм күрсәтү кысаларында бирелгән, «торак» һәм «торак корыма» билгеләнеше булган биналардан, «торак» һәм «торак урын» билгеләнеше булган бүлмәләрдән тыш; мөрәҗәгать итүче һәм (яки) аның Россия Федерациясе Торак кодексының 51 статьясының 1 өлешендәге 4 пункты нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән, бер фатирда гражданнарның бергә яшәү мөмкинлеген бирми торган хроник авыруларның катлаулы формалары исемлегендә каралган хроник авыруның катлаулы формасыннан интегә торган гаилә әгъзасы биләп торган торак урыннан (фатирның, бүлмәнең бер өлешеннән) тыш; билгеләнгән тәртиптә яшәү өчен яраксыз дип танылган торак урыннан тыш);

суммар мәйданы гаилә әгъзалары санына 40 кв.метр тапкырчыгышыннан күбрәк булган, «торак йорт» билгеләнеше белән ике һәм аннан күбрәк бина (Россия Федерациясе субъектының вәкаләтле органы яисә муниципаль берәмлек тарафыннан күпбалалы гаиләгә социаль ярдәм күрсәтү кысаларында бирелгән, «торак йорт» билгеләнеше булган бинадан тыш; торак урынның гомуми мәйданында өчтән бер өлешеннән артык булмаган өлешендә торак урынга гомуми өлешле милекчелек

хокукындагы өлештән тыш; мөрәҗәгать итүче һәм (яки) аның Россия Федерациясе Торак кодексының 51 статьясының 1 өлешендәге 4 пункты нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән, бер фатирда гражданнарның бергә яшәү мөмкинлеген бирми торган хроник авыруларның катлаулы формалары исемлегендә каралган хроник авыруның катлаулы формасыннан интегә торган гаилә әгъзасы биләп торган торак урыннан (торак йортның бер өлешеннән) тыш; билгеләнгән тәртиптә яшәү өчен яраксыз дип танылган торак урыннан тыш);

«бакча йорты» билгеләнеше белән ике һәм аннан күбрәк бина;

«торак булмаган» билгеләнеше булган ике һәм аннан күбрәк бина, «торак булмаган» билгеләнешле бүлмәләр, корылмалар (индивидуаль торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен билгеләнгән җир кишәрлекләрендә, бакча җир кишәрлекләрендә урнашкан хуҗалык корылмаларыннан, шулай ук күпфатирлы йортта гомуми милек булып торган күчемсез мөлкәт объектларыннан, бакчачылык яки яшелчәчелек коммерциясез ширкәтенең гомуми файдалану милеге булып торган күчемсез мөлкәт объектларыннан тыш);

транспорт чаралары куеп тору (саклау), аларны ремонтлау һәм техник хезмәт күрсәтү өчен билгеләнгән ике һәм аннан күбрәк күчемсез милек объекты (гараж, машина урыны) (өч һәм аннан күбрәк шундый күчемсез мөлкәт объекты – күпбалалы гаиләләр өчен; составында инвалид булган гаиләләр; Россия Федерациясе субъектының вәкаләтле органы яки муниципаль берәмлек тарафыннан күпбалалы гаиләгә социаль ярдәм чаралары бирү кысаларында авто- яки мототранспорт чарасы бирелгән гаиләләр өчен);

суммар мәйданы 0,25 гектардан артып китә торган, ә авыл җирлекләре территориясе яисә авылара территорияләр өчен бер гектардан артып китә торган җир кишәрлекләре (гомуми өлешле милектә торган җир кишәрлекләреннән һәм «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр әйләнеше турында» федераль закон белән әйләнеше җайга салына торган авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән, Россия Федерациясе субъектының вәкаләтле органы яисә муниципаль берәмлек тарафыннан социаль ярдәм чаралары бирү кысаларында күпбалалы гаиләгә бирелгән җир кишәрлекләреннән, «Дәүләт яки муниципаль милектә торган һәм Ерак көнчыгыш федераль округы составына керә торган Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә урнашкан җир кишәрлекләрен гражданнарга бирү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон нигезендә бирелгән җир кишәрлекләреннән тыш);

д) мөрәҗәгать итүчегә яки аның гаилә әгъзаларына түбәндәгеләрнең теркәлгән булуы:

ике һәм аннан күбрәк автотранспорт чарасы (өч һәм аннан күбрәк автотранспорт чарасы – күпбалалы гаиләләр, составында инвалид булган гаиләләр, автотранспорт чарасы Россия Федерациясе субъектының вәкаләтле органы яки муниципаль берәмлек тарафыннан социаль ярдәм чаралары күрсәтү кысаларында бирелгән гаиләләр өчен);

ике һәм аннан күбрәк мототранспорт чарасы (өч һәм аннан күбрәк мототранспорт чарасы – күпбалалы гаиләләр, составында инвалид булган гаиләләр, мототранспорт чарасы Россия Федерациясе субъектының вәкаләтле органы яки

муниципаль берәмлек тарафыннан социаль ярдәм чаралары күрсәтү кысаларында бирелгән гаиләләр өчен);

двигателенең куәте 250 ат көченнән ким булмаган, чыгарылган елы биш елдан артмаган автотранспорт чарасы, дүрт һәм аннан күбрәк балалы гаилә алган (сатып алган), биштән артык урыны булган автотранспорт чарасыннан тыш;

чыгарылган елы биш елдан артмаган ике һәм аннан күбрәк кече суднолар (әлеге абзац таләбе 2022 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

чыгарылган елы биш елдан артмаган ике һәм аннан күбрәк үзйөрешле машина һәм башка төр техника (әлеге абзац таләбе 2022 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

е) мөрәҗәгать итүчедә һәм аның гаилә әгъзаларында айлык түләү билгеләү өчен мөрәҗәгат итү датасына Россия Федерациясе буенча билгеләнгән, тулаем алганда халыкның җан башына исәпләгәндә яшәү минимумы күләмен арттырып җибәрә торган, кредит оешмаларында ачылган депозит счетларында (кертемнәрендә) калган акчага исәпләнгән процентлар рәвешендә керемнәр булуы;

ж) мөрәҗәгать итүчедә яки аның гаиләсенең эшкә яраклы әгъзаларында (18 яше тулмаган яшьтәге балалардан тыш) Айлык акчалата түләү билгеләү тәртибе һәм шартларының 31 пунктында каралган чорга Тәртип һәм шартларның 30 пунктындагы «а», «б» (в части пенсий), «в», «е», «к», «м»-«о», «р» пунктчаларында каралган керемнәрнең булмавы, әлеге чорга туры килә торган түбәндәге (җыеп исәпләгәндә) очраклардан тыш:

мөрәҗәгать итүченең яки аның эшли торган гаилә әгъзаларының алты айдан артыграк эшсезлек статусында булуы;

мөрәҗәгать итүче яки аның гаилә әгъзалары баланы өч яше тулганчы карап торган очракта;

23 яшьтән кечерәк мөрәҗәгать итүченең яки аның гаилә әгъзаларының гомуми белем бирү оешмасында, һөнәри белем бирү оешмасында яисә югары белем бирү мәгариф оешмасында көндезге форма буенча укуы һәм стипендия алмавы;

мөрәҗәгать итүче яки аның гаилә әгъзаларының 18 яшенә кадәрге инвалид-баланы яки балачактан I төркем инвалидны яисә I төркем инвалидны яисә 80 яшенә җитеп, дәвалау оешмасы бәяләмәсе белән даими рәвештә читләр тәрбиясенә мохтаж дип танылган өлкән кешене каравы;

мөрәҗәгать итүченең яки аның гаилә әгъзаларының өч айдан артык вакыт дәвамында дәвалануы, шуның нәтиҗәсендә вакытлыча хезмәт эшчәнлеген башкара алмавы;

мөрәҗәгать итүченең яки аның гаилә әгъзаларының хәрби хезмәт узуы (демобилизация көненә кадәр өч айдан артмаган чорны да кертеп);

мөрәҗәгать итүченең яки аның гаилә әгъзаларының иректән мәхрүм ителүе (ирекккә чыгу көненә кадәр өч айдан артмаган чорны да кертеп);

мөрәҗәгать итүченең балигълык яшенә җитмәгән балаларның бердәнбер ата-анасы (законлы вәкиле) булып торуы (булуы);

мөрәҗәгать итүченең яки аның күпбалалы гаиләсендә бер әгъзасының керемнәр алмавы.

Әлеге пунктта күрсәтелгән нигезләр буенча керемнәр булмау чорлары тулаем бәяләнә. Әлеге Айлык акчалата түләү тәртибе һәм шартларының 31 пунктында

каралган керемнәр булмаган чор җыеп исәпләгәндә исәп-хисап чорының 10 һәм аннан күбрәк аен тәшкил итсә, түләү билгеләүдән (яңадан исәпләүдән) баш тарту турында карар кабул ителми;

3) үзенә карата гариза алынган баланың сигез яшен тутыруы, Тәртип һәм шартларның 3 пунктындагы өченче абзацында каралган очрактан тыш;

и) мөрәҗәгать итүче тарафыннан Үзәк бүлекчәсенә Тәртип һәм шартларның 16 пунктында күрсәтелгән документларның (белешмәләрнең) («ф» һәм «ц» пунктчаларыннан тыш), шулай ук Тәртип һәм шартларның 17 һәм 18 пунктларында күрсәтелгән чорларда документларның (белешмәләрнең) тапшырылмавы;

л) үзенә карата гариза тапшырыла торган балага карата башка законлы вәкилгә айлык акчалата түләү билгеләнү фактының билгеләнүе;

л) мөрәҗәгать итүче тарафыннан Тәртип һәм шартларның 23 пункты нигезендә гариза һәм (яки) документлар эшләп бетерү өчен кире кайтарылганнан соң биш эш көне эчендә кирәкле гаризаның һәм (яки) документларның тапшырылмавы.»;

2.9 пунктта «2.9.1.» саннарын төшереп калдырырга;

2.10 пунктта «2.10.1.» саннарын төшереп калдырырга;

2.11 пунктта «2.11.1.» саннарын төшереп калдырырга;

2.13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.13. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатен теркәү вакыты һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада да

2.13.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гариза кирәкле барлык документлары белән гариза алынган көнне теркәлә.

2.13.2. Ял (бәйрәм) көнендә электрон формада килгән гариза ял (бәйрәм) көненнән соңгы ял (бәйрәм) көне булып саналмаган эш көнендә, ә гариза эш көне тәмамланганнан соң алынган очракта, икенче эш көнендә теркәлә.»;

2.15 пунктта:

2.15.2 пунктының беренче абзацында «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталында» сүзләрен «Бердәм порталда» сүзләренә алмаштырырга;

2.15.3 пунктының сигезенче абзацында «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталы» сүзләрен «Бердәм портал» сүзләренә алмаштырырга;

2.16 пунктында «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталы» сүзләрен тиешле саннарда һәм килеш кушымчаларында кулланып, «Бердәм портал» сүзләренә алмаштырырга;

3 нче бүлектә:

3.3 пунктның 3.3.4 пунктчасында «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталы» сүзләрен тиешле саннарда һәм килеш кушымчаларында кулланып, «Бердәм портал» сүзләренә алмаштырырга;

3.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү

Үзәк бүлекчәсе белгече айлык акчалата түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар турында мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт

хезмәте күрсәтү турындагы гаризада күрсәтелгән ысул белән (мөрәҗәгать итүченең почта адресына язмача формада, электрон почта адресы буенча электрон документ формасында, телефонга СМС-хәбәр җибәреп) хәбәр итә.

Әлеге пунктта каралган процедураларны үтәү срогы:

мөрәҗәгать итүчегә айлык акчалата түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар турында хәбәр итү айлык акчалата түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар имзаланган көнне гамәлгә ашырыла.

Айлык акчалата түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул итү турында хәбәр юлланган мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу өчен шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта, айлык акчалата түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту турында) карар күчермәсен бирү мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә айлык акчалата түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар турында хәбәр итү яисә мөрәҗәгать итүчгә айлык акчалата түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар күчермәсен шәхсән тапшыру.»;

Регламентка 1 нче кушымтаның нумерацияле баш исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Өч яшьтән җиде яшькә кадәрге балага айлык акчалата түләү билгеләү һәм аны түләп бару буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

Регламентка 2 нче кушымтаның нумерацияле баш исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Өч яшьтән җиде яшькә кадәрге балага айлык акчалата түләү билгеләү һәм аны түләп бару буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

Регламентка 3 нче кушымтаның нумерацияле баш исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Өч яшьтән җиде яшькә кадәрге балага айлык акчалата түләү билгеләү һәм аны түләп бару буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта»;

Регламентка 4 нче кушымтаның нумерацияле баш исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Өч яшьтән җиде яшькә кадәрге балага айлык акчалата түләү билгеләү һәм аны түләп бару буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 4 нче кушымта»;

Регламентка (белешмәлек) кушымтада:

нумерацияле баш исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Өч яшьтән җиде яшькә кадәрге балага айлык акчалата түләү билгеләү һәм аны түләп бару буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (белешмәлек) нче кушымта»;

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Өч яшьтән җиде яшькә кадәрге балага айлык акчалата түләү билгеләү һәм аны түләп бару буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында мәгълүматлар».